КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 12 апрель г.Казань № 281

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль район-нары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә теркәлгән 2 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр

округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 494 нче, 2016 ел, 15 февраль, 73 нче, 2016 ел, 7 ноябрь, 823 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1093 нче; 2018 ел, 22 сентябрь, 828 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә теркәлгән 2 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 20 нче һәм 20.1 нче пунктлар өстәп, үзгәреш кертергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «20 | Кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә, үзмәшгульләрне теркәүне исәпкә алып, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп эшләүче кешеләр санының пландагы күрсәткечләрен үтәү (үсүче нәтиҗә белән),% | Татарстан Республика-сы Икътисад министрлыгы | квартал саен (үсә баручы нәтиҗә белән) | V=A/B×100, монда: A – кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә мәшгуль кешеләрнең факттагы саны, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп, үзмәшгульләрне теркәүне исәпкә алып, кеше; B – кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә мәшгуль кешеләрнең пландагы саны, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп, үзмәшгульләрне теркәүне исәпкә алып, кеше». |
| 20.1 | шул исәптән үзмәшгульләр саны буенча планлаштырылган күрсәткечләргә ирешү,% | | | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин